СОВЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Кооперативная, д. 22, с.Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районының**
**Утар-Аты авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 05 » ноябрь 2024 ел.** **№ 127**

**Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» 2022 елның 25 февралендәге 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (14.12.2023 №105 үзгәрешләре белән)**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән Утар-Аты авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында “Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Советының 2022 елның 25 февралендәге 49 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Утар-Аты авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә (14.12.2023 N 105 үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

a. 4.6 пунктның 4.6.8 подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«4.6.8. Рейд тикшерүе прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, моңа 248-ФЗ Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3-5 пунктлары һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12_1 өлешләре нигезендә үткәрелгән очраклар керми»;

b. 4.8 пунктның 4.8.4. подпунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

«4.8.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча “Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында” 2020 елның 31 июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http:arsk.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Утар-Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г.Мөхәмәтгалиева